ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 с.Старое Дрожжаное № 560

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» Муниципаль казна учреждениесе уставына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 24.08.2017 ел № 466 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» Муниципаль казна учреждениесе уставына түбәндәге эчтәлекле 10 бүлек белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«10. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу

10.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы астында Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм шул чакта Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм үзе хезмәткәр булып торган Учреждениенең милкенә һәм (яки) оешманың эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар килеп чыгарга мөмкин.

10.2. Хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруга тәэсир итүче яки йогынты ясарга мөмкин булган Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы астында, Учреждение хезмәткәренең акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән үз-үзе өчен яки өченче затлар өчен милек хокуклары яки мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлатыла.

10.3. Учреждение директоры гамәлгә куючыга вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксыну турында хәбәр итәргә тиеш.

10.4. Учреждение хезмәткәре Учреждение директорына вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә бурычлы.

мәгълүматлар исемлеге, бу мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет Җитәкчесе: Д. Ә. Сатдинов